ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ «ГОРОД АГРЫЗ»
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ӘГЕРҖЕ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕНЕН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

КАРАР ПОСТАНОВЛЕНИЕ

29.12.2025 Әгерҗе ш. № 26

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлегендә 2026 елга торак урыннарны карап тоткан өчен түләү күләмен үзгәртү турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексының 158 статьясындагы 4 өлеше, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2018 елның 6 апрелендәге 213/пр номерлы «Торак урын милекчеләре өчен күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында, торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү буенча методик тәкъдимнәр раслау турында, шулай ук мондый түләүнең чик индексларын билгеләү тәртибен билгеләү турында карар, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты КАРАР ИТТЕ**:**

1. 2025 елга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлегендә торак урыннарны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен үзгәртү буенча иң чик индексны расларга:
2026 елның 1 гыйнварыннан 2026 елның 30 сентябренә кадәр чорда 17,7 процент күләмендә;
2026 елның 1 октябреннән 2026 елның 31 декабренә кадәрге чорда 18,2 процент күләмендә.
2. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (http://agryz.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының “Әгерҗе шәһәре” муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Л.Р. Шәриповка йөкләргә.

Җитәкче И.Б. Гыйззәтуллин